Россия Федерациясе Урман кодексының 30 статьясы 4, 5 кисәкләре, 83 статьясы 12 кисәге 4 пункты, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм урман турындагы законнарның үтәлешен тәэмин итү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен, сатулар уздырмыйча, урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзүе» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына әлеге Указ нигезендә расланган Административ регламентка, законнарда каралган очракларда, билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәрне вакытында бирүне тәэмин итәргә.

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Үзагач әзерләү хокукы бирү һәм шәхси ихтыяҗлар өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре проектын әзерләү турында карар кабул итү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2022 елның 3 февралендәге ПУ-80 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 12 апрелендәге 231 номерлы

Указына кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 4 пункты.

4. Әлеге Указ рәсми бастырып чыгарылган көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 14 декабрь
№ 964

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның « 14 » декабрендәге
964 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен, сатулар уздырмыйча, урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзүе» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен, сатулар уздырмыйча, урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзүе» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – дәүләт хезмәте) дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартларын, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәүгә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, Административ регламентны үтәүне контрольдә тоту рәвешләре, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының (алга таба шулай ук – Министрлык) һәм аның вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенең – урманчылыкның һәм аның хезмәткәрләренең, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең (алга таба – күпфункцияле үзәк), күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе билгеләнә.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар – дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) белән Министрлыкка мөрәҗәгать иткән гражданнар (алга таба – гариза бирүче) яисә аларның вәкаләтле вәкилләре (алга таба – вәкил).

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчегә (вәкилгә) гариза бирүченең анкета тутыруы нәтиҗәсендә (алга таба – профильләштерү), шулай ук гариза бирүче (вәкил) хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буенча аның билгеләнгән сыйфатларына туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү варианты (алга таба шулай ук – вариант) нигезендә күрсәтелергә тиеш.

1.4. Вариант әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасындагы 1 нче таблица нигезендә билгеләнә.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче Министрлык, аның структур бүлекчәләре турында белешмә мәгълүмат Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://minleshoz.tatarstan.ru) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (www.uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы), «Федераль дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.gosuslugi.ru), «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал) урнаштырыла.

1.6. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүматны түбәндәгеләрдән алырга мөмкин:

1) Министрлыкның гариза бирүчеләр (вәкилләр) белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматлар кертелгән дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмати элмә такталардан (алга таба – элмә такта);

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән:

Министрлыкның рәсми сайтында;

Республика порталында;

Бердәм порталда;

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.7. Министрлыкның рәсми сайтында, Министрлыкның гариза бирүчеләр (вәкилләр) белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмати элмә такталарда, Республика порталында, Бердәм порталда гариза бирүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү максатында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

1) дәүләт хезмәтенең атамасы;

2) гариза бирү мөмкинлеге булган затлар исемлеге;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге, әлеге документларны тутыруга таләпләр;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү барышында тормышка ашырылган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерү хокукы турында мәгълүмат;

7) Министрлыкның эш вакыты, Министрлык белгечләренең дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча кабул итү графигы турында мәгълүмат.

Әлеге пунктта күрсәтелгән мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында һәм Республика порталында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

Министрлык әлеге мәгълүматның вакытында яңартылып торуын тәэмин итә.

1.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми рәвештә бастыру чыганакларын күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында, Бердәм порталда, «Федераль дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## II. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы: гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен, сатулар уздырмыйча, урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзүе (алга таба – урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү).

2.2. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түбәндәгеләр җаваплы: Министрлыкның структур бүлекчәсе – дәүләт урман реестры, урманнардан файдалану һәм урман төзелеше бүлеге (алга таба – Бүлек) һәм аның чикләрендә урман утыртмаларын салып алу күздә тотылган урманчылык территориясендә вәкаләтләр башкаручы тиешле Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе – урманчылык (алга таба – Урманчылык).

Дәүләт хезмәте гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту мөмкинлеге бирелмәгән гариза кабул итү өлешендә күпфункцияле үзәк аша күрсәтелә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында Министрлык башка органнар белән хезмәттәшлек итми.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе түбәндәгеләр:

1) гариза бирүче (вәкил) урман утыртмаларын сату- алу өчен шартнамә төзүне сорап мөрәҗәгать иткәндә:

устав нигезендә эш итүче Урманчылык җитәкчесе-урманчы йөзендә Министрлык һәм гариза бирүче (вәкил) тарафыннан кул куелган электрон рәвештәге яисә кәгазьдәге урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе;

гариза бирүченең (вәкилнең) күрсәтелгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүче (вәкил) тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында Министрлык хаты рәвешендә рәсмиләштерелгән карар;

2) гариза бирүче (вәкил) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү өчен мөрәҗәгать иткәндә:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында Министрлык хаты рәвешендә рәсмиләштерелгән хәбәрнамә (алга таба – хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамә);

Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хаты;

устав нигезендә эш итүче Урманчылык җитәкчесе-урманчы йөзендә Министрлык һәм гариза бирүче (вәкил) тарафыннан кул куелган электрон рәвештәге яисә кәгазьдәге урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү;

гариза бирүче (вәкил) тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куелмавы турында Урманчылык хаты рәвешендә рәсмиләштерелгән хәбәрнамә.

2.5. Гариза бирүчегә (вәкилгә) дәүләт хезмәте түбәндәге юллар белән күрсәтелә:

2.5.1. Гариза бирүче (вәкил) урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү өчен мөрәҗәгать иткәндә:

1) гаризаны Министрлыкка шәхсән үзе, почта яисә күпфункцияле үзәк аша биргәндә, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә (вәкилгә) шәхсән тапшырыла яисә аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәлгән хат рәвешендә почта аша кәгазь чыганакта яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсен алуның сайланган ысулына карап, электрон почта адресына юллана;

2) гариза Республика порталы яисә Бердәм портал аша бирелгәндә:

гариза бирүчегә (вәкилгә), аның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап кайсы портал аша мөрәҗәгать итүенә бәйле рәвештә, Бердәм порталдагы яисә Республика порталындагы шәхси кабинетында дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең әзер булуы турында хәбәрнамә җибәрелә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә гариза бирүченең (вәкилнең) Бердәм порталдагы яисә Республика порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә;

гариза бирүче (вәкил) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алуны сайлаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе гариза бирүчегә (вәкилгә) шәхсән тапшырыла яисә почта аша, аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә җибәрелә;

гариза бирүче (вәкил) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон почта адресына җибәрүне сайлаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе электрон почта адресына җибәрелә.

2.5.2. Гариза бирүче (вәкил) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү турында мөрәҗәгать итсә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә (вәкилгә) шәхсән тапшырыла, гариза бирүче (вәкил) күрсәткән электрон

почта адресына юллана яисә аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә җибәрелә.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар Министрлыкта, Республика порталында, Бердәм порталда теркәлгән көннән 10 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар күпфункцияле үзәк аша бирелгәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар Министрлыкта теркәлгән көннән 10 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

2.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында, Бердәм порталда, «Федераль дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында, Бердәм порталда урнаштырылган.

2.8. Законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге, аларның гариза бирүче (вәкил) мөстәкыйль төстә бирергә тиешле документларга һәм мәгълүматларга, гариза бирүче (вәкил) үз теләге белән бирергә хокуклы документларга бүленеше белән, әлеге Административ регламентның III кисәгендә китерелгән.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

2.11. Дәүләт хезмәтен гариза кергәнче алдан әзерләү (проактив) режимында күрсәтү очраклары булганы юк.

2.12. Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты куйган ставкалар буенча билгеләнә.

2.13. Гариза биргән вакытта Министрлыкта яисә күпфункцияле үзәктә, шулай ук Урманчылыкта дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтү вакыты 15 минуттан да артырга тиеш түгел.

2.14. Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны теркәү вакыты – гариза Министрлыкка алынган көннән бер эш көне.

Эш көнендә 18:00 гә кадәр бирелгән гариза Министрлыкта кергән көнендә теркәлә. Эш көнендә 18:00 дән соң яисә эш көне булмаган көнне бирелгән гариза Министрлыкта икенче эш көнендә теркәлә.

2.15. Министрлыкның гариза бирүчеләр (вәкилләр) белән эшләү биналарында дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүмат бирелгән элмә такталар куела. Министрлыкның, күпфункцияле үзәк биналарының ал ягында Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең атамасы турында мәгълүмат урнаштырыла.

Гариза бирүчеләргә (вәкилләргә) документлар тутыру өчен урындыклар, өстәлләр куелган кабул итүне көтү урыннары бүлеп бирелә.

Бина санитар таләпләргә һәм нормаларга туры китереп җиһазландырылырга тиеш.

Министрлык, күпфункцияле үзәк инвалидлар (кресло-коляскадан һәм юл күрсәтүче этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) өчен түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

гариза бирүчеләр (вәкилләр) белән эшләү биналарына тоткарлыксыз керү өчен шартлар булдыруны;

гариза бирүчеләр (вәкилләр) белән эшләү биналары урнаштырылган территориядә мөстәкыйль хәрәкәт итү, әлеге биналарга керү һәм алардан чыгу, шул исәптән кресло-коляска файдаланып, транспортка утыру һәм аннан чыгу өчен мөмкинлекләрне;

күрү функциясе һәм гариза бирүчеләр (вәкилләр) белән эшләү биналары урнаштырылган территориядә мөстәкыйль хәрәкәт итү сәләте ягыннан дәвалап булмый торган авырулары булган инвалидларны озатып йөрүне, аларга кирәкле ярдәм күрсәтүне;

инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләнгәнлеген исәпкә алып, аларның гариза бирүчеләр (вәкилләр) белән эшләү биналарына тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазлар һәм мәгълүмат чыганаклары урнаштыруны;

инвалидлар өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә бирелә һәм укыла торган мәгълүматны һәм шулай ук язмаларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм графикалы мәгълүматны рельеф-нокталы Брайль шрифты белән язылган билгеләр ярдәмендә кабатлап бирүне, бинага сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертүне;

гариза бирүчеләр (вәкилләр) белән эшләү бинасына, аның махсус өйрәтелгән булуын раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Юл күрсәтүче этнең махсус өйрәтелгән булуын һәм аны бирү тәртибен раслый торган документ формасын раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы карары нигезендә расланган форма һәм тәртип буенча бирелә торган документ булганда, юл күрсәтүче этне кертүне;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең, Урманчылык хезмәткәрләренең инвалидларның башка затлар белән бер дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалана алуына комачаулык итүче киртәләрне узуда ярдәм итүен.

Гариза бирүчеләр (вәкилләр) белән эшләү биналарын инвалидлар мәнфәгатьләрен исәпкә алып тулысынча үзгәртеп кору мөмкин булмаганда, әлеге затларны дәүләт хезмәте күрсәтү урынына алып килү тәэмин ителә яисә, мөмкин булганда, хезмәтне тору урыны буенча яки дистанцион режимда күрсәтү тәэмин ителә.

Министрлык, күпфункцияле үзәк биналары янындагы территорияләрдә транспорт кую урыннары ясала.

2.16. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалана алу һәм аның сыйфатлы булуы дәрәҗәсе түбәндәгеләр нигезендә бәяләнә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында гражданнарның хәбәрдар булуы дәрәҗәсе (дәүләт хезмәте турында мәгълүматның ачыклыгы, мәгълүмат алу ысулын сайлау мөмкинлеге);

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срокларының һәм дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта административ процедуралар (гамәлләр) срокларының үтәлүе;

3) дәүләт хезмәтен Республика порталы яисә Бердәм портал аша электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчедән (вәкилдән) нигезле шикаятьләрнең булмавы;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итү;

6) дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтен күрсәтү варианты нигезендә күрсәтү.

Гариза бирүчегә (вәкилгә) Бердәм порталда, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалана алу дәрәҗәсен һәм аның сыйфатлы булуын бәяләү мөмкинлеге бирелә.

2.17. Гариза бирүченең (вәкилнең) Министрлыкның вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлеге түбәндәгечә башкарыла:

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны гариза бирүче (вәкил) шәхсән тапшырганда – 15 минуттан да артык түгел;

гариза бирүче (вәкил) дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен кәгазь чыганакта шәхсән алганда – 15 минуттан да артык түгел;

гариза бирүче (вәкил) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының Урманчылыкның һәм аның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шәхсән шикаять биргәндә – 15 минуттан да артык түгел.

2.18. Гариза бирүченең (вәкилнең) күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре белән хезмәттәшлеге түбәндәгечә башкарыла:

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны гариза бирүче (вәкил) шәхсән тапшырганда – 15 минуттан да артык түгел;

гариза бирүче (вәкил) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының Урманчылыкның һәм аның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шәхсән шикаять биргәндә – 15 минуттан да артык түгел.

2.19. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны, Министрлыкка телдән (шәхсән яисә телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтыннан, Республика порталыннан, Бердәм порталдан алырга була.

2.20. Гариза бирүче (вәкил) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза белән күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Күпфункцияле үзәк, гариза алынгач, күпфункцияле үзәк һәм Министрлык арасында хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, ләкин гариза күпфункцияле үзәккә кергән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча, аның Министрлыкка тапшырылуын тәэмин итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза күпфункцияле үзәккә бирелгән очракта, дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

Комплекслы сорату буенча дәүләт хезмәте күрсәтү каралмаган.

2.21. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәгеләр тормышка ашырыла:

1) гариза бирүчегә (вәкилгә) әлеге Административ регламентта билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат бирү һәм гариза бирүченең (вәкилнең) дәүләт хезмәте турында мәгълүматлардан файдалана алуын тәэмин итү;

2) гариза бирүченең (вәкилнең) кайсын сайлавына карап, Республика порталы һәм Бердәм портал аша, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны компьютер программасы ярдәмендә укыла торган форматтагы электрон документ рәвешендә Министрлыкка җибәрү;

3) гариза бирүченең (вәкилнең) дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алуы;

4) гариза бирүченең (вәкилнең) Республика порталы һәм Бердәм порталдагы шәхси кабинетында дәүләт хезмәте күрсәтүнең көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ шәкелендә нәтиҗәсен алуы;

5) әлеге Административ регламентның V кисәгендә билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү.

2.22. Гариза бирүче (вәкил) Республика порталы яисә Бердәм портал аша электрон рәвештә гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

1) гамәл кылуга хокукын раслау;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри мәгълүматлардан торган компьютер программасы ярдәмендә укыла торган форматтагы электрон гариза формасын ачу һәм тутыру;

3) электрон гариза формасына электрон рәвештәге документларны яисә документларның электрон нөсхәләрен беркетү;

4) хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген, шулай ук шәхси белешмәләрне эшкәртүгә килешүне раслау;

5) әлеге Административ регламент таләпләренә туры китереп, электрон гаризага имза кую;

6) тутырылган электрон гаризаны җибәрү һәм аның җибәрелүе расланган тиешле хәбәрнамә алу.

2.23. Республика порталында, Бердәм порталда гаризаның электрон формасы урнаштырыла. Гариза бирүче (вәкил) тарафыннан гаризаның электрон формасының һәр юлы тутырылганнан соң аның бердәй электрон сервис форматына туры килү-килмәве тикшерелә. Гаризаның электрон формасында юлларның тиешенчә тутырылмавы ачыкланган очракта, гариза бирүчегә (вәкилгә) нәкъ менә шушы күрсәтелгән электрон формада нинди хата китүе һәм аны төзәтү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр бирелә.

2.24. Документларны Республика порталында, Бердәм порталда электрон рәвештә тапшырганда гариза бирүчегә (вәкилгә) түбәндәге мөмкинлекләр бирелә:

1) элегрәк кертелгән мәгълүматны саклаган хәлдә, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына әйләнеп кайту;

2) гариза бирүченең (вәкилнең) Бердәм порталда һәм Республика порталында элегрәк аның тарафыннан тапшырылган документлардан, әлеге документлар тапшырылган вакыттан кимендә бер ел дәвамында файдалана алуы.

2.25. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә файдаланыла торган мәгълүмат системалары: Республика порталы, Бердәм портал.

2.26. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризага, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларга һәм (яисә) мәгълүматка «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гариза бирүченең (вәкилнең) электрон имзасы куела.

## III. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураларның составы, башкару эзлеклелеге һәм сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедуралар (гамәлләр) башкару үзенчәлекләре

### Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге

3.1. Гариза бирүче (вәкил) урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү өчен мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте түбәндәге вариантлар буенча күрсәтелә:

1 вариант: мөстәкыйль мөрәҗәгать иткән физик зат;

2 вариант: аның исеменнән ышанычнамә белән вәкиле мөрәҗәгать иткән физик зат.

3.2. Гариза бирүче (вәкил) урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсендә җибәрелгән хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү өчен мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте түбәндәге вариантлар буенча күрсәтелә:

3 вариант: мөстәкыйль мөрәҗәгать иткән физик зат;

4 вариант: аның исеменнән ышанычнамә белән вәкиле мөрәҗәгать иткән физик зат.

3.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документның дубликатын бирү каралмаган.

## Гариза бирүченең гомуми сыйфатлары тасвирламасы

3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү варианты Министрлыкта, күпфункцияле үзәктә яисә Республика порталы яисә Бердәм порталда гариза бирүченең анкета тутыру юлы белән башкарыла торган гомуми сыйфатларын тасвирлау нигезендә билгеләнә һәм гариза бирүчеләрнең әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасындагы 2 нче таблицада күрсәтелгән, гариза бирүчеләрнең гомуми сыйфатлары исемлеген ачыкларга мөмкинлек бирә торган мәсьәләләрдән тора.

3.5. Гариза бирүченең анкета сорауларына җавап бирүе нәтиҗәләре буенча әлеге Административ регламент нигезендә сыйфатлар мәгънәләре комбинацияләренең тулы исемлеге билгеләнә, аларның һәрберсе вариантларның берсенә туры килә.

## 1 вариант

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гаризаның һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның Министрлыкта, Республика порталында, Бердәм порталда теркәлгән көннән 10 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар күпфункцияле үзәк аша бирелгәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гаризаның һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның Министрлыкта теркәлгән көненнән 10 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе түбәндәгеләр:

устав нигезендә эш итүче Урманчылык җитәкчесе-урманчы йөзендә Министрлык һәм гариза бирүче (вәкил) тарафыннан кул куелган электрон рәвештәге яисә кәгазьдәге урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе;

урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында Министрлык хаты рәвешендә рәсмиләштерелгән карар;

гариза бирүченең күрсәтелгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамә;

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедуралардан тора:

1) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү – гариза алынган көннән бер эш көне;

2) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карап тикшерү, гариза бирүчегә (вәкилгә) урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамә юллап, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карар кабул итү яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүдән баш тарту турында карар кабул итү – гариза теркәлгән көннән дүрт эш көне;

3) Урманчылык тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе проектын әзерләү, урман утыртмаларын тикшерү, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирү һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул кую – урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзелү турындагы карар алынганнан соң биш эш көне;

4) гариза бирүчегә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүдән баш тарту турында яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карар кабул итү яисә гариза бирүченең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамәне юллау – урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүдән баш тарту турында яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карарга кул куелган яисә гариза бирүченең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелган көннән бер эш көне.

**Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү**

3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге:

1) әлеге Административ регламентка 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры (алга таба – министр) исеменә гариза, анда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлү адресы, шәхесен таныклый торган документ мәгълүматлары;

аның чикләрендә урман утыртмалары сату-алу күздә тотылган урманчылыкның атамасы;

соратылган үзагачның күләме, аның сыйфат күрсәткечләре һәм аны әзерләү максаты.

Гариза бирүче гаризада үз теләге белән башка белешмәләр бирергә хокуклы;

2) әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык – гаризаны Министрлыкка шәхсән үзе, почта аша яисә күпфункцияле үзәк аша биргәндә.

3.10. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гаризаның бланкын гариза бирүче Министрлыкка, күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында, Бердәм порталда урнаштырыла.

Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге юлларның берсе белән бирелергә (юлланырга) мөмкин:

шәхсән;

почта аша;

күпфункцияле үзәк аша;

Республика порталын яисә Бердәм порталны файдаланып.

3.11. Гариза бирүченең шәхесен таныклау (тәңгәлләштерү) ысуллары:

Министрлыкта, күпфункцияле үзәктә – шәхесне таныклый торган документ;

Республика порталында яисә Бердәм порталда – гариза бирүченең электрон имзасын тикшерү;

почта аша җибәргәндә – шәхесне таныклау таләп ителми.

3.12. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнары карамагында булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны бирүе Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган.

3.13. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат – Министрлыкның оештыру эше бүлеге башлыгы.

3.14. Министрлыкның оештыру эше бүлеге вазыйфаи заты Министрлыкка гариза кергән көнне түбәндәгеләрне башкара:

1) гаризаны һәм бирелгән документларны терки;

2) Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүчегә документларны кабул итү датасы һәм гаризаның аны кабул итү номеры куелган күчермәсен бирә;

3) гариза Республика порталы яисә Бердәм портал аша бирелгән очракта, гариза бирүчегә гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү турында электрон рәвештә хәбәрнамә җибәрә;

4) бирелгән документларны теркәп, гаризаны министрга җибәрә.

3.15. Административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсендә дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бирелгән гариза теркәлә, аңа документлар өстәлә, алар министрга җибәрелә.

**Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карап тикшерү, гариза бирүчегә (вәкилгә) урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамә юллап, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карар кабул итү яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүдән баш тарту турында карар кабул итү**

3.16. Теркәлгән гаризаның һәм аңа өстәп бирелгән документларның Бүлек белгеченә бирелүе административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.17. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат Бүлек башлыгы була.

3.18. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

3.19. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр түбәндәгеләр:

1) төгәл яки тулы булмаган яисә әлеге Административ регламентның 3.9. пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән документлар тапшыру;

2) гаризада күрсәтелгән үзагачны әзерләү күләме гражданнарга шәхси ихтыяҗлары өчен үзагач әзерләүнең «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы 1 кисәгендә билгеләнгән нормаларыннан артып китүе;

3) гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән урманчылыкта гаризада күрсәтелгән үзагач әзерләү өчен таләп ителгән сыйфат күрсәткечләренә туры килә торган урман утыртмаларының җитәрлек булмавы;

4) «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы 1 кисәге нигезендә билгеләнгән срокларның үтәлмәве.

3.20.Теркәлгән гариза бирелгән көннән дүрт эш көне дәвамында Бүлекнең вазыйфаи заты:

1) гаризаны һәм аңа өстәп бирелгән документларны карап тикшерүне тәэмин итә;

2) урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамә юллап, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карар проектын әзерләүне, әлеге карарга Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кул куелуны һәм гариза бирүчегә (вәкилгә) әлеге карарны алуны тәэмин итә торган теләсә кайсы юл белән аны тапшыруны (шул исәптән почта, факс элемтәсе һәм электрон почта аша) яисә юллауны тәэмин итә;

3) урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карарны Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан кул куелган көнне аны алуны тәэмин итә торган теләсә кайсы юл белән (шул исәптән почта, факс элемтәсе һәм электрон почта аша) Урманчылыкка юллауны тәэмин итә.

3.21. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга әлеге Административ регламентның 3.19 пунктында каралган нигезләр булганда, Бүлекнең вазыйфаи заты теркәлгән гариза бирелгән көннән дүрт эш көне дәвамында урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар проектын әзерләүне һәм әлеге карарга Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кул куелуны тәэмин итә.

3.22. Кул куелган һәм гариза бирүчегә һәм Урманчылыкка юлланган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында карар яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**Урманчылык тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе проектын әзерләү, урман утыртмаларын тикшерү, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирү һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул кую**

3.23. Министрлыкның урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карарының, гаризаның һәм аңа өстәп бирелгән документларның Урманчылыкка керүе административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.24. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат – Урманчылык җитәкчесе-урманчы.

3.25. Урманчылык белгече Министрлыкның урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карары Урманчылыкка кергән көннән дүрт эш көне дәвамында урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе проектын әзерләүне, гариза бирүче белән берлектә урман утыртмаларын тикшерә, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирүне һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куюны тәэмин итә.

3.26. Гариза бирүче урман утыртмаларын тикшерү, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирү һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе проектына кул кую өчен Урманчылыкка гариза бирүчегә Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән көнне килергә тиеш.

3.27. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе кәгазь чыганакта ике нөсхәдә Министрлыкта гариза теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында яки, гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап кайсы портал аша мөрәҗәгать итүенә карап, электрон документ рәвешендә Республика порталында яисә Бердәм порталда гариза Республика порталында яисә Бердәм порталда теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында төзелә.

Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә Республика порталында яисә Бердәм порталда электрон документ рәвешендә кул куелган очракта, Урманчылык белгече урман утыртмаларын тикшерү уздырылган, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирелгән көнне урман

утыртмаларын сату-алу шартнамәсе проектын Республика порталына яисә Бердәм порталга кертә.

3.28. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча Министрлык сатучы буларак эш итә, ә Министрлык исеменнән урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә Урманчылык җитәкчесе-урманчы кул куя.

3.29. Түбәндәге шартларның берсе гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тартуы дип кабул ителә:

гариза бирүченең Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве;

гариза бирүченең урман утыртмалары тикшерелгәннән, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирелгәннән соң Министрлыкта гариза теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында кәгазь чыганакта урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы;

гариза бирүченең (вәкилнең) урман утыртмалары тикшерелгәннән, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирелгәннән соң гариза Республика порталында яисә Бердәм порталда теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында, гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап кайсы портал аша мөрәҗәгать итүенә карап, Республика порталында яисә Бердәм порталда электрон документ рәвешендәге урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы.

Әлеге пунктның икенче-дүртенче абзацларында күрсәтелгән очракларда, Урманчылык белгече гариза бирүченең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамә проектын әзерләүне һәм аңа Урманчылык җитәкчесе-урманчының кул куюын тәэмин итә.

3.30. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзелү яисә гариза бирүченең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында имзаланган хәбәрнамә проекты административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**Гариза бирүчегә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарны яки урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен яисә гариза бирүченең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамә юллау**

3.31. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында имзаланган карар яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзелү яисә гариза бирүченең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман

утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында имзаланган хәбәрнамә административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.32. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат:

Бүлек башлыгы – урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта;

Урманчылык җитәкчесе-урманчы – урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзелү яисә гариза бирүченең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамә имзалану очрагында.

3.33. Бүлекнең вазыйфаи заты белгече урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарга кул куелган көннән бер эш көне дәвамында:

1) урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарның бер нөсхәсен гариза бирүчегә шәхсән тапшыра яисә кәгазь чыганакта аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә почта аша җибәрә яки электрон почтага юллый (дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алуның кайсы ысулын сайлавына бәйле рәвештә);

2) гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гаризаны Республика порталы яисә Бердәм портал аша биргән очракта, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар гариза бирүченең шәхси кабинетына җибәрелә. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алу ысулы сайлап алынган очракта, әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән административ процедуралар (гамәлләр) башкарыла.

3.34. Урманчылык белгече урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә яисә гариза бирүченең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелган көннән бер эш көне дәвамында:

1) ике як тарафыннан имзаланган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенең бер нөсхәсен яисә гариза бирүченең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамәләрне гариза бирүчегә шәхсән тапшыра яисә кәгазь чыганакта аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә почта аша җибәрә яки электрон почтага юллый (дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алуның кайсы ысулын сайлавына бәйле рәвештә);

2) гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гаризаны Республика порталы яисә Бердәм портал аша биргән очракта, ике як тарафыннан имзаланган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе яисә гариза бирүченең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен

Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамә гариза бирүченең шәхси кабинетына җибәрелә. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алу ысулы сайлап алынган очракта, әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән административ процедуралар (гамәлләр) башкарыла.

3.35. Гариза бирүчегә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар яисә ике як тарафыннан имзаланган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе яисә гариза бирүченең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамә юллану административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**2 вариант**

3.36. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар Министрлыкта, Республика порталында, Бердәм порталда теркәлгән көннән 10 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар күпфункцияле үзәк аша юлланганда, дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар Министрлыкта теркәлгән көннән 10 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

3.37. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе түбәндәгеләр:

устав нигезендә эш итүче Урманчылык җитәкчесе-урманчы йөзендә Министрлык һәм вәкил тарафыннан кул куелган электрон рәвештәге яисә кәгазьдәге урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе;

урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар;

вәкилнең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) вәкил тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында хәбәрнамә;

3.38. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедуралардан тора:

1) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү – гариза алынган көннән бер эш көне;

2) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карап тикшерү, вәкилнең урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамә юллап, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карар кабул итү яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүдән баш тарту турында карар кабул итү – гариза теркәлгән көннән дүрт эш көне;

3) Урманчылык тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе проектын әзерләү, урман утыртмаларын тикшерү, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирү һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул кую – урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзелү турындагы карар алынганнан соң биш эш көне;

4) вәкилгә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүдән баш тарту турында яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карар кабул итү яисә вәкилнең күрсәтелгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамәне юллау – урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүдән баш тарту турында яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карарга кул куелган яисә вәкилнең күрсәтелгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелган көннән бер эш көне.

**Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү**

3.39. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге:

1) әлеге Административ регламентка 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча министр исеменә гариза, анда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлү адресы, шәхесен таныклый торган документ мәгълүматлары;

вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), корреспонденция өчен адресы;

аның чикләрендә урман утыртмалары сату-алу күздә тотылган урманчылыкның атамасы;

соратылган үзагачның күләме, аның сыйфат күрсәткечләре һәм аны әзерләү максаты.

Гариза бирүче гаризада үз теләге белән башка белешмәләр бирергә хокуклы;

2) затның (вәкилнең) гариза бирүче исеменнән эш йөртергә вәкаләтләрен раслый торган, граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән документ;

3) әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык – гаризаны Министрлыкка шәхсән үзе, почта аша яисә күпфункцияле үзәк аша биргәндә.

3.40. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гаризаның бланкын вәкил Министрлыкка, күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга

мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында, Бердәм порталда урнаштырыла.

Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар вәкил тарафыннан түбәндәге юлларның берсе белән бирелергә (юлланырга) мөмкин:

шәхсән;

почта аша;

күпфункцияле үзәк аша;

Республика порталын яисә Бердәм порталны файдаланып.

3.41. Вәкилнең шәхесен таныклау (тәңгәлләштерү) ысуллары:

Министрлыкта, күпфункцияле үзәктә – шәхесне таныклый торган документ;

Республика порталында яисә Бердәм порталда – вәкилнең электрон имзасын тикшерү;

почта аша җибәргәндә – шәхесне таныклау таләп ителми.

3.42. Вәкилнең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнары карамагында булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны бирүе Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган.

3.43. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат – Министрлыкның оештыру эше бүлеге башлыгы.

3.44. Министрлыкның оештыру эше бүлеге вазыйфаи заты Министрлыкка гариза кергән көнне түбәндәгеләрне башкара:

1) гаризаны һәм бирелгән документларны терки;

2) Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкилгә документларны кабул итү датасы һәм гаризаның аны кабул итү номеры куелган күчермәсен бирә;

3) гариза Республика порталы яисә Бердәм портал аша бирелгән очракта, вәкилгә гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү турында электрон рәвештә хәбәрнамә җибәрә;

4) бирелгән документларны теркәп, гаризаны министрга җибәрә.

3.45. Административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсендә дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бирелгән гариза теркәлә, аңа документлар өстәлә, алар министрга җибәрелә.

**Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карап тикшерү, вәкилгә урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамә юллап, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карар кабул итү яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүдән баш тарту турында карар кабул итү**

3.46. Теркәлгән гаризаның һәм аңа өстәп бирелгән документларның Бүлек белгеченә бирелүе административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.47. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат Бүлек башлыгы була.

3.48. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

3.49. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр түбәндәгеләр:

1) төгәл яки тулы булмаган яисә әлеге Административ регламентның 3.39. пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән документлар тапшыру;

2) гаризада күрсәтелгән үзагачны әзерләү күләме гражданнарга шәхси ихтыяҗлары өчен үзагач әзерләүнең «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы 1 кисәгендә билгеләнгән нормаларыннан артып китүе;

3) гаризада күрсәтелгән урманчылыкта гаризада әйтелгән үзагач әзерләү өчен таләп ителгән сыйфат күрсәткечләренә туры килә торган урман утыртмаларының җитәрлек булмавы;

4) «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы 1 кисәге нигезендә билгеләнгән срокларның үтәлмәве.

3.50.Теркәлгән гариза бирелгән көннән дүрт эш көне дәвамында Бүлекнең вазыйфаи заты:

1) гаризаны һәм аңа өстәп бирелгән документларны карап тикшерүне тәэмин итә;

2) урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамә юллап, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карар проектын әзерләүне, әлеге карарга Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кул куелуны һәм вәкилгә аны тапшыруны яисә әлеге карарны алуны тәэмин итә торган теләсә кайсы юл белән (шул исәптән почта, факс элемтәсе һәм электрон почта аша) юллауны тәэмин итә;

3) урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карарны Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан кул куелган көнне аны алуны тәэмин итә торган теләсә кайсы юл белән (шул исәптән почта, факс элемтәсе һәм электрон почта аша) Урманчылыкка юллауны тәэмин итә.

3.51. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тартуга әлеге Административ регламентның 3.49 пунктында каралган нигезләр булганда, Бүлекнең вазыйфаи заты теркәлгән гариза бирелгән көннән дүрт эш көне дәвамында урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар проектын әзерләүне һәм әлеге карарга Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кул куелуны тәэмин итә.

3.52. Кул куелган һәм вәкилгә һәм Урманчылыкка юлланган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында карар яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**Урманчылык тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе проектын әзерләү, урман утыртмаларын тикшерү, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирү һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул кую**

3.53. Министрлыкның урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карарының, гаризаның һәм аңа өстәп бирелгән документларның Урманчылыкка керүе административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.54. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат – Урманчылык җитәкчесе-урманчы.

3.55. Урманчылык белгече Министрлыкның урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү турында карары Урманчылыкка кергән көннән дүрт эш көне дәвамында урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе проектын әзерләүне, вәкил белән берлектә урман утыртмаларын тикшерүне, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирүне һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе проектына кул куюны тәэмин итә.

3.56. Вәкил урман утыртмаларын тикшерү, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирү һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе проектына кул кую өчен вәкилгә Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән көнне Урманчылыкка килергә тиеш.

3.57. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе кәгазь чыганакта ике нөсхәдә Министрлыкта гариза теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында яки, вәкил дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап кайсы портал аша мөрәҗәгать итүенә карап, электрон документ рәвешендә Республика порталында яисә Бердәм порталда гариза Республика порталында яисә Бердәм порталда теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында төзелә.

Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә Республика порталында яисә Бердәм порталда электрон документ рәвешендә кул куелган очракта, Урманчылык белгече урман утыртмаларын тикшерү уздырылган, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирелгән көнне урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе проектын Республика порталына яисә Бердәм порталга кертә.

3.58. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча Министрлык сатучы буларак эш итә, ә Министрлык исеменнән урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә Урманчылык җитәкчесе-урманчы кул куя.

3.59. Түбәндәге шартларның берсе вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тартуы дип кабул ителә:

вәкилгә Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән көнне вәкилнең урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве;

вәкилнең урман утыртмалары тикшерелгәннән, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирелгәннән соң Министрлыкта гариза теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында кәгазь чыганакта урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы;

вәкилнең урман утыртмалары тикшерелгәннән, урман утыртмаларын кисү өчен кишәрлек бүлеп бирелгәннән соң гариза Республика порталында яисә Бердәм порталда теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында, вәкил дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап кайсы портал аша мөрәҗәгать итүенә карап, Республика порталында яисә Бердәм порталда электрон документ рәвешендәге урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы.

Әлеге пунктның икенче–дүртенче абзацларында күрсәтелгән очракларда, Урманчылык белгече вәкилнең күрсәтелгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамә проектын әзерләүне һәм аңа Урманчылык җитәкчесе урманчының кул куюын тәэмин итә.

3.60. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзелү яисә вәкилнең күрсәтелгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында имзаланган хәбәрнамә проекты административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

## Вәкилгә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарны яки урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен яисә вәкилнең күрсәтелгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамә юллау

3.61. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында имзаланган карар яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзелү яисә вәкилнең күрсәтелгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында имзаланган хәбәрнамә административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.62. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат:

Бүлек башлыгы – урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта;

Урманчылык җитәкчесе-урманчы – урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзелү яисә вәкилнең күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве һәм (яисә) вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамә имзалану очрагында.

3.63. Бүлекнең вазыйфаи заты урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарга кул куелган көннән бер эш көне дәвамында:

1) урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарның бер нөсхәсен вәкилгә шәхсән тапшыра яисә кәгазь чыганакта аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә почта аша җибәрә яки электрон почтага юллый (дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алуның кайсы ысулын сайлавына бәйле рәвештә);

2) вәкил гаризаны Республика порталы яисә Бердәм портал аша биргән очракта, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарны вәкилнең шәхси кабинетына юллый. Вәкил дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алуны сайлаган очракта, әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гамәлләр башкарыла.

3.64. Урманчылык белгече урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә яисә вәкилнең билгеләнгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве турында һәм (яисә) вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелган көннән бер эш көне дәвамында:

1) ике як тарафыннан имзаланган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенең яисә вәкилнең билгеләнгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве турында һәм (яисә) вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамәнең бер нөсхәсен вәкилгә шәхсән тапшыра яисә кәгазь чыганакта аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә почта аша җибәрә яки электрон почтага юллый (дәүләт хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен алуның кайсы ысулын сайлавына бәйле рәвештә);

2) вәкил гаризаны Республика порталы яисә Бердәм портал аша биргән очракта, ике як тарафыннан имзаланган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенең яисә вәкилнең билгеләнгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве турында һәм (яисә) вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамәнең бер нөсхәсен вәкилнең шәхси кабинетына юллый. Вәкил дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алуны сайлаган очракта, әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән административ процедуралар (гамәлләр) башкарыла.

3.65. Вәкилгә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарны яисә ике як тарафыннан имзаланган урман

утыртмаларын сату-алу шартнамәсен яисә вәкилнең билгеләнгән вакытта урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килмәве турында һәм (яисә) вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә кул куймавы турында хәбәрнамәне юллау административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**3 вариант**

3.66. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар Министрлыкта теркәлгән көннән 10 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар күпфункцияле үзәк аша бирелгәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гаризаның һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның Министрлыкта теркәлгән көненнән 10 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

3.67. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамә;

Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хаты;

устав нигезендә эш итүче Урманчылык җитәкчесе-урманчы йөзендә Министрлык һәм гариза бирүче тарафыннан кул куелган, кәгазь чыганакта урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү;

гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамә.

3.68. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә түбәндәге административ процедуралар керә:

1) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү – гариза кергән көннән бер эш көне;

2) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карап тикшерү, хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карарга кул кую – гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән дүрт эш көне;

3) Урманчылык тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү проектын әзерләү һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куелу – Урманчылыкка Министрлыкның урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карары килгән көннән биш эш көне дәвамында;

4) хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәне, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатын яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүне яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын

сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәне гариза бирүчегә юллау – хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелган көннән бер эш көне.

## Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү

3.69. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге: министр исеменә хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү турында ирекле шәкелдә төзелгән язма рәвештә бирелгән гариза, анда түбәндәге мәгълүматлар китерелә:

гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлү адресы, шәхесен таныклый торган документ мәгълүматлары;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенең реквизитлары;

хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булу фактын раслый торган документлар (белешмәләр).

Гариза бирүче гаризада үз теләге белән башка белешмәләр бирергә хокуклы.

3.70. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге юлларның берсе белән бирелергә (юлланырга) мөмкин:

шәхсән;

почта аша;

күпфункцияле үзәк аша.

3.71. Гариза бирүченең шәхесен таныклау (тәңгәлләштерү) ысуллары:

Министрлыкта, күпфункцияле үзәктә – шәхесне таныклый торган документ;

почта аша юллаганда – шәхесне таныклау таләп ителми.

3.72. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат – Министрлыкның оештыру эше бүлеге башлыгы.

3.73. Министрлыкның оештыру эше бүлеге вазыйфаи заты Министрлыкка гариза кергән көнне түбәндәгеләрне башкара:

1) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны терки;

2) Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүчегә документларны кабул итү датасы һәм гаризаның аны кабул итү номеры куелган күчермәсен бирә;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны теркәп, гаризаны министрга җибәрә.

3.74. Административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсендә дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бирелгән гариза теркәлә, аңа документлар өстәлә, алар министрга җибәрелә.

**Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карап тикшерү, хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карарга кул куелу**

3.75. Теркәлгән гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның Бүлек белгеченә бирелүе административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.76. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат – Бүлек башлыгы.

3.77. Әлеге Административ регламентның 3.69 пунктында билгеләнгән таләпләрне үтәмичә төзелгән гариза дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

3.78. Бүлекнең вазыйфаи заты гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны теркәгән көннән дүрт эш көне дәвамында:

1) гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның карап тикшерелүен тәэмин итә;

2) түбәндәгеләрне тәэмин итә:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документларда хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмаган очракта, хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамә проектын әзерләүне һәм әлеге хәбәрнамәгә Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан кул куелуны;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 3.77 пунктында каралган нигезләр булганда, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хаты проектын әзерләүне һәм әлеге хатка Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан кул куелуны;

гариза бирүчегә урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамә юллап, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карар проектын әзерләүне, әлеге карарга Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан кул куелуны һәм гариза бирүчегә әлеге карарны алуны тәэмин итә торган теләсә кайсы юл белән аны тапшыруны (шул исәптән почта, факс элемтәсе һәм электрон почта аша) яисә юллауны;

3) урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карарны аңа Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан кул

куелган көнне Урманчылык тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү проектын әзерләү өчен кәгазь чыганакта аны алуны тәэмин итә торган теләсә кайсы юл белән (шул исәптән почта, факс элемтәсе һәм электрон почта аша) Урманчылыкка юллауны.

3.79. Хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатына кул куелу яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карарга кул куелу һәм аны гариза бирүчегә һәм Урманчылыкка юллау административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**Урманчылык тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү проектын әзерләү һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куелу**

3.80. Министрлыкның урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карарының Урманчылыкка килүе административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.81. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат – Урманчылык җитәкчесе-урманчы.

3.82. Урманчылык белгече Министрлыкның урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карары Урманчылыкка килгән көннән биш эш көне дәвамында урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү проектын әзерләүне һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куелуны тәэмин итә.

3.83. Гариза бирүче Урманчылыкка гариза бирүчегә Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул кую өчен килергә тиеш.

3.84. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү Министрлыкта гариза теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында язма рәвештә ике нөсхәдә төзелә.

3.85. Министрлык исеменнән урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә Урманчылык җитәкчесе-урманчы кул куя.

3.86. Гариза бирүченең Министрлыкта гариза теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында кәгазь чыганакта урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүне төзүдән баш тартуы дип кабул ителә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән очракта, Урманчылык белгече гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамә проектын әзерләүне һәм әлеге хәбәрнамәгә Урманчылык җитәкчесе-урманчы тарафыннан кул куелуны тәэмин итә.

3.87. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзелү яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелу административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**Хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәне, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатын яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүне яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәне гариза бирүчегә юллау**

3.88. Хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелу административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.89. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы затлар түбәндәгеләр:

Бүлек башлыгы – хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хаты имзалану очрагында;

Урманчылык җитәкчесе-урманчы – урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамә имзалану очрагында.

3.90. Бүлекнең вазыйфаи заты хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тарту турында Министрлыкның хатына кул куелган көннән бер эш көне дәвамында хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәнең, хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тарту турында Министрлыкның хатының бер нөсхәсен кәгазь чыганакта гариза бирүчегә шәхсән тапшыра яисә аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә почта аша яисә электрон почта адресына юллый.

3.91. Урманчылык белгече урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелган көннән бер эш көне дәвамында Урманчылык белгече ике як тарафыннан имзаланган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүнең яки гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәнең бер

нөсхәсен кәгазь чыганакта гариза бирүчегә шәхсән тапшыра яисә аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә почта аша яисә электрон почта адресына юллый.

3.92. Хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәне, хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тарту турында Министрлыкның хатын яисә ике як тарафыннан имзаланган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүне яки гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәне гариза бирүчегә юллау административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**4 вариант**

3.93. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар Министрлыкта теркәлгән көннән 10 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар күпфункцияле үзәк аша бирелгәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гаризаның һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның Министрлыкта теркәлгән көненнән 10 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

3.94. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамә;

Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хаты;

устав нигезендә эш итүче Урманчылык җитәкчесе-урманчы йөзендә Министрлык һәм вәкил тарафыннан кул куелган, кәгазь чыганакта урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү;

гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамә.

3.95. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә түбәндәге административ процедуралар керә:

1) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү – гариза кергән көннән бер эш көне;

2) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карап тикшерү, хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карарга кул кую – гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән дүрт эш көне;

3) Урманчылык тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү проектын әзерләү һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куелу – Урманчылыкка

Министрлыкның урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карары килгән көннән биш эш көне дәвамында;

4) хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәне, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатын яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүне яисә вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәне вәкилгә юллау – хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә яисә вәкилнең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелган көннән бер эш көне.

## Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү

3.96. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге:

1) министр исеменә хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү турында иркле шәкелдә төзелгән язма рәвештә бирелгән гариза, анда түбәндәге мәгълүматлар китерелә:

гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны (чынлыкта тору урыны) буенча теркәлү адресы, шәхесен таныклый торган документ реквизитлары;

вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), корреспонденция өчен адресы;

вәкилгә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенең реквизитлары;

хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булу фактын раслый торган документлар (белешмәләр).

Вәкил гаризада үз теләге белән башка белешмәләр бирергә хокуклы;

2) вәкаләтле затның (вәкилнең) гариза бирүче исеменнән эш йөртүгә вәкаләтләрен раслый торган, граждан законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән документ.

3.97. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге юлларның берсе белән бирелергә (юлланырга) мөмкин:

шәхсән;

почта аша;

күпфункцияле үзәк аша.

3.98. Гариза бирүченең шәхесен таныклау (тәңгәлләштерү) ысуллары:

Министрлыкта, күпфункцияле үзәктә – шәхесне таныклый торган документ;

почта аша юллаганда – шәхесне таныклау таләп ителми.

3.99. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат – Министрлыкның оештыру эше бүлеге башлыгы.

3.100. Министрлыкның оештыру эше бүлеге вазыйфаи заты Министрлыкка гариза кергән көнне түбәндәгеләрне башкара:

1) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны терки;

2) Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүчегә документларны кабул итү датасы һәм гаризаның аны кабул итү номеры куелган күчермәсен бирә;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны теркәп, гаризаны министрга җибәрә.

3.101. Административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсендә дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бирелгән гариза теркәлә, аңа документлар өстәлә, алар министрга җибәрелә.

**Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карап тикшерү, хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тарту турында Министрлыкның хатына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карарга кул куелу**

3.102. Теркәлгән гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның Бүлек белгеченә бирелүе административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.103. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат – Бүлек башлыгы.

3.104. Әлеге Административ регламентның 3.96 пунктында билгеләнгән таләпләрне үтәмичә төзелгән гариза дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

3.105. Бүлекнең вазыйфаи заты гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны теркәгән көннән дүрт эш көне дәвамында:

1) гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның карап тикшерелүен тәэмин итә;

2) түбәндәгеләрне тәэмин итә:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документларда хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмаган очракта, хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамә проектын әзерләүне һәм әлеге хәбәрнамәгә Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан кул куелуны;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 3.104 пунктында каралган нигезләр булганда, хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тарту турында

Министрлык хаты проектын әзерләүне һәм әлеге хатка Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан кул куелуны;

гариза бирүчегә урман утыртмаларын тикшерү өчен Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамә юллап, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карар проектын әзерләүне, әлеге карарга Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан кул куелуны һәм гариза бирүчегә әлеге карарны алуны тәэмин итә торган теләсә кайсы юл белән аны тапшыруны (шул исәптән почта, факс элемтәсе һәм электрон почта аша) яисә юллауны;

3) урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карарны аңа Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан кул куелган көнне Урманчылык тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү проектын әзерләү өчен кәгазь чыганакта аны алуны тәэмин итә торган теләсә кайсы юл белән (шул исәптән почта, факс элемтәсе һәм электрон почта аша) Урманчылыкка юллауны.

3.106. Хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тарту турында Министрлыкның хатына кул куелу яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карарга кул куелу һәм аны гариза бирүчегә һәм Урманчылыкка юллау административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**Урманчылык тарафыннан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү проектын әзерләү һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куелу**

3.107. Министрлыкның урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карарының Урманчылыкка килүе административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.108. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы зат – Урманчылык җитәкчесе-урманчы.

3.109. Урманчылык белгече Министрлыкның урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карары Урманчылыкка килгән көннән биш эш көне дәвамында урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү проектын әзерләүне һәм урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куелуны тәэмин итә.

3.110. Гариза бирүче Урманчылыкка гариза бирүчегә Урманчылыкка килү кирәклеге турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән көнне урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул кую өчен килергә тиеш.

3.111. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү Министрлыкта гариза теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында язма рәвештә ике нөсхәдә төзелә.

3.112. Министрлык исеменнән урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә Урманчылык җитәкчесе-урманчы кул куя.

3.113. Гариза бирүченең Министрлыкта гариза теркәлгән көннән тугыз эш көне дәвамында кәгазь чыганакта урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүне төзүдән баш тартуы дип кабул ителә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән очракта, Урманчылык белгече гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамә проектын әзерләүне һәм әлеге хәбәрнамәгә Урманчылык җитәкчесе-урманчы тарафыннан кул куелуны тәэмин итә.

3.114. Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешү төзелү яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелу административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**Хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәне, хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тарту турында Министрлыкның хатын яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүне яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәне вәкилгә юллау**

3.115. Хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелу административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

3.116. Административ процедураны (гамәлне) башкару өчен җаваплы затлар түбәндәгеләр:

Бүлек башлыгы – хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хаты имзалану очрагында;

Урманчылык җитәкчесе-урманчы – урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамә имзалану очрагында.

3.117. Бүлекнең вазыйфаи заты хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәгә, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатына кул куелган көннән бер эш көне дәвамында хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар

булмавы турында хәбәрнамәнең, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатының бер нөсхәсен кәгазь чыганакта вәкилгә шәхсән тапшыра яисә аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә почта аша яисә электрон почта адресына юллый.

3.118. Урманчылык белгече урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә яисә гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәгә кул куелган көннән бер эш көне дәвамында Урманчылык белгече ике як тарафыннан имзаланган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүнең яки гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәнең бер нөсхәсен кәгазь чыганакта вәкилгә шәхсән тапшыра яисә аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә почта аша яисә электрон почта адресына юллый.

3.119. Хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамәне, Министрлыкның хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы турында хатын яисә ике як тарафыннан имзаланган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүне яки гариза бирүченең урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенә өстәмә килешүгә кул куймавы турында хәбәрнамәне вәкилгә юллау административ процедураны (гамәлне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

## IV. Административ регламентны үтәүне контрольдә тоту рәвешләре

4.1. Урманчылыкның вазыйфаи затлары һәм хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләре үтәлешен агымдагы контрольдә тоту тәртибе һәм нинди вакыт аралыгында башкарылырга тиешлеге Министрлыкның карары нигезендә билгеләнә.

4.2. Әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләре үтәлешенә агымдагы контроль Министрлыкның җаваплы вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын тикшерү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә карарлар кабул итүгә контроль рәвешендә алып барыла.

4.3. Агымдагы контроль дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдә турыдан-туры катнаша торган Министрлыкның вазыйфаи затларының һәм Урманчылык хезмәткәрләренең әлеге Административ регламентның, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының нигезләмәләрен үтәвен тикшерү юлы белән башкарыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүдән, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очракларын ачыклау һәм бетерүдән, гариза бирүчеләрнең Министрлыкның вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләре кертелгән мөрәҗәгатьләрен карап тикшерүдән, алар буенча карарлар кабул итүдән һәм җаваплар әзерләүдән, шулай ук әлеге Административ регламентның нигезләмәләре үтәлешен тикшерүдән тора. Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан тикшерү даими, һәръяклы һәм объектив булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерүләр планлы һәм планнан тыш була ала.

Планлы тикшерүләр Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан Министрлыкның карары белән расланган тикшерүләр уздыру планы нигезендә кимендә елга бер тапкыр үткәрелә.

Планнан тыш тикшерүләр гариза бирүченең Министрлыкның вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителгән карарларына яисә башкарган гамәлләренә (гамәл кылмаулары) карата шикаяте (дәгъвасы) нигезендә уздырыла.

Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә контроль телефон аша телдән мәгълүмат, шулай ук соратуга җавап буларак язмача мәгълүмат яисә электрон рәвештә мәгълүмат алу юлы белән башкарыла.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.6 Министрлыкның җаваплы вазыйфаи затлары әлеге Административ регламентның сроклары һәм процедуралары үтәлеше, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителгән карарлар, гамәлләр (гамәл кылмау) өчен шәхсән җаваплы була.

Министрлыкның җаваплы вазыйфаи затларының шәхси җаваплылыгы Министрлык карары, вазыйфаи регламентлар нигезендә билгеләнә.

4.7. Гариза бирүченең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда тикшерү йомгаклары буенча гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

## V. Министрлыкның һәм аның вазыйфаи затларының, Урманчылыкның һәм аның хезмәткәрләренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Шикаятьне бирү һәм карап тикшерү тәртибе турындагы мәгълүматны түбәндәге ысуллар белән алырга була:

1) мәгълүмати элмә такталардан;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән:

Министрлыкның рәсми сайтында;

Республика порталында;

Бердәм порталда;

3) Министрлыкка телдән (телефон аша яки шәхсән) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән, Министрлыкның рәсми сайты аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

5.2. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына), Урманчылык җитәкчесе-урманчының, Урманчылык хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять гариза бирүче (вәкил) тарафыннан министр исеменә кәгазь чыганакта (почта аша яисә гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә), электрон рәвештә, шулай ук күпфункцияле үзәк аша бирелә.

Министрның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять гариза бирүче (вәкил) тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына язма рәвештә кәгазь чыганакта (почта аша), шулай ук электрон рәвештә бирелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять гариза бирүче (вәкил) тарафыннан күпфункцияле үзәк директорына кәгазь чыганакта (почта аша яисә гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә), шулай ук электрон рәвештә бирелә.

Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять гариза бирүче (вәкил) тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына кәгазь чыганакта (почта аша яисә гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә), шулай ук электрон рәвештә бирелә.

5.3. Электрон рәвештә шикаять гариза бирүче тарафыннан түбәндәгеләр аша тапшырылырга мөмкин:

1) Министрлыкның рәсми сайты;

2) Республика порталы;

3) Бердәм портал;

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә чыгарылган карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен, сатулар уздырмыйча, урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзүе» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

## Гариза бирүченең гомуми сыйфатлары, шулай ук һәркайсы дәүләт хезмәте күрсәтү вариантларының берсенә туры килә торган сыйфат мәгънәләре комбинацияләре

**1 нче таблица. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантларына туры килә торган гариза бирүчеләр исемлеге**

| Вариантның номеры | Сыйфат мәгънәләре комбинацияләре |
|---|---|
| **Гариза бирүче сорап мөрәҗәгать итә торган дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе: «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен, сатулар уздырмыйча, урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзүе»** | |
| 1 | Мөстәкыйль мөрәҗәгать иткән физик зат |
| 2 | Аның исеменнән ышанычнамә белән вәкиле мөрәҗәгать иткән физик зат |
| **Гариза бирүче сорап мөрәҗәгать итә торган дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе: «Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документларда ясалган хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү»** | |
| 3 | Мөстәкыйль рәвештә мөрәҗәгать иткән физик зат |
| 4 | Аның исеменнән ышанычнамә белән вәкиле мөрәҗәгать иткән физик зат |

**2 нче таблица. Гариза бирүченең гомуми сыйфатлары тасвирламасы**

| Т/с | Гариза бирүченең сыйфаты | Гариза бирүченең сыйфат мәгънәләре комбинацияләре |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүченең категориясе | 1. Физик зат |
| 2 | Хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән зат | 1. Мөстәкыйль мөрәҗәгать иткән физик зат.<br>2. Ышанычнамә белән физик зат исеменнән эш алып барырга хокуклы зат (вәкил) |

______________

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен, сатулар уздырмыйча, урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзүе» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы
урман хуҗалыгы министрына

____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме
(соңгысы – булган очракта)

**Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен, сатулар уздырмыйча, урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүгә гариза**

20___ елның «___» _____________

1. Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)________________________________________________________.

2. Шәхесне таныклый торган документның реквизитлары: ________________________________,_________серияле _________ номерлы,
(шәхесне таныклый торган документның төре)

______________________________________________________________________.
(кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

3. Яшәү урыны (чынлыкта тору урыны) буенча теркәлү адресы (почта индексын күрсәтеп*):

______________________________________________________________________.

4. Элемтә өчен телефон номеры (номерлары)*:________________________.

Электрон почта адресы**:______________________________________.

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә ____________________________________________ максатларында
(үзагач әзерләүнең максатын күрсәтергә)

________________________________________сыйфат күрсәткечләренә ия
(токымның составы, эшкә яраклы, утын әзерләү өчен)
__________куб метр үзагач күләмендә ____________________________________
урманчылыгы чикләрендә сатулар уздырмыйча, шәхси ихтыяҗлар өчен урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзүне сорыйм.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен юллауны яисә бирүне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетка***
☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталындагы шәхси кабинетка***
☐ кәгазь чыганакта шәхсән
☐ электрон почта адресына
☐ кәгазь чыганакта почта аша

_________________________________/_____________/
(фамилия, исем, атаның исеме (соңгысы – булган очракта) / имза)

___________

Искәрмәләр:

* Бу мәгълүматны күрсәтү гариза бирүче ихтыярында.

** Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен электрон почта адресына алу ысулын сайлаган очракта күрсәтелә.

*** Гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы һәм Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша бирелгән очракта тутырыла.

___________

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен, сатулар уздырмыйча, урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Форма

**Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

20___ елның «___» ________

Мин, ______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
_________________________________, ________ серияле_______ номерлы,
(шәхесне таныклаучы документның төре)
______________________________________________________________,
(кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
_____________________________________________адресы буенча яшәүче, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан минем шәхси белешмәләремне тикшерүгә ризалык бирәм һәм әлеге ризалыкны биргәндә, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә эш йөртүемне раслыйм.

Әлеге ризалык минем тарафтан «Сатулар уздырмыйча, гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү» дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында бирелә һәм түбәндәге мәгълүматларга кагыла: фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), туган вакыт, яшәү урыны буенча теркәлү адресы, паспорт белешмәләре.

Әлеге ризалык югарыда күрсәтелгән максатка ирешү өчен кирәкле булган минем шәхси белешмәләремә бәйле теләсә нинди гамәлләр кылу, минем шәхси белешмәләремне җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), алардан файдалану, тарату, шәхескә бәйләнешсез бетерү, гамәлен туктату, юкка чыгару, шулай ук федераль законнар нигезендә башка гамәлләр кылу өчен бирелә.

Минем тарафтан бирелгән шәхси белешмәләр законсыз файдаланылган очракта әлеге ризалык минем язма гаризам нигезендә кире алына.

Әлеге ризалык 20____ елның «___» ________ шәхси ихтыяҗлар өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсенең гамәле вакыты беткәнчегә кадәр гамәлдә.

______________________________________________/__________________
(ризалык биргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) / имзасы)

____________